ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

06.04.2017 Казань № 21

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2013 елның 04 декабрендәге 94 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең норматив-хокукый актларын федераль законнарга туры китерү максатларында

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Шушы боерыкка кушымта булып килүче, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2013 елның 04 декабрендәге 94 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2016 елның 26 июлендәге 48 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне (алга таба – Үзгәрешләр, Регламент) расларга.

2. Бу боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә, шушы боерык белән расланган Үзгәрешләрнең 4 пунктыннан, 5 пунктының “а” пунктчасыннан, 9, 10, 18 пунктларыннан кала, алар 2017 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең хокук идарәсе юридик бүлегенә бу боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең җыелма анализ бүлегенә Регламентны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту җаваплылыгын үз өстемә алам.

Башлык в.б. И.Ф. Сафиуллин

**Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2013 елның 04 декабрендәге 94 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2016 елның 26 июлендәге 48 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр**

1. 1.2 пункт:

а) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан зарури таләпләр бозылуларны кисәтү, зарури таләпләр бозылуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару максатларында, Инспекция ел саен раслана торган бозуларны профилактикалау программасы нигезендә зарури таләпләрне бозуларны профилактикалау буенча чараларны гамәлгә ашыра.”;

б) түбәндәге эчтәлекле 1.2.1 пунктын өстәргә:

“1.2.1. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыручы затларның түбәндәге билгеләмәләре кулланыла:

а) вазыйфаи зат – Инспекциянең территориаль органының Инспекция башлыгы (башлыгы урынбасары) боерыгы нигезендә билгеле бер капиталь төзелеш объектында законнар нигезендә төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен җаваплы итеп билгеләнгән, шул исәптән Регламентта каралган гамәлләрнең тиешенчә һәм үз вакытында гамәлгә ашырылышы өчен җаваплы булган хезмәткәре;

б) төркем җитәкчесе – Инспекция башлыгы (башлыгы урынбасары) боерыгы нигезендә вазыйфаи затлар арасыннан билгеләнә торган, оештыру һәм координацияләү өчен җаваплы булган, шулай ук дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча вазыйфаи затларның, шул исәптән Регламентта каралган гамәлләрнең тиешенчә һәм үз вакытында гамәлгә ашырылышы буенча эшчәнлегенә җитәкчелек итүче зат;

в) вазыйфаи затларны билгеләү турында боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча җаваплы зат – Инспекциянең территориаль органының Инспекция башлыгы (башлыгы урынбасары) боерыгы нигезендә билгеләнә торган, вазыйфаи затлар тарафыннан төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелегенең тиешенчә гамәлгә ашырылуын, шул исәптән Регламентта каралган гамәлләрнең гамәлгә ашырылуын контрольдә тотучы хезмәткәре”;

2. 1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.3. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге түбәндәгеләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексы (алга таба – РФ КоАП) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2002, № 1 (1 өл.),1 ст, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясенең Арбитраж процессуаль кодексы (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2002, № 30, 3012 ст, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – РФ ШрК) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2005, № 1 (1 өл.), 16 ст, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

“Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

“Куркыныч сәнәгать объектларының сәнәгый иминлеге турында” 1997 елның 21 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 1997, № 30, 3588 ст, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

“Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында” 1999 елның 30 декабрендәге 52-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 1999, № 14, 1650 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында” 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 73-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2002, № 26, 2519 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

“Техник җайга салу турында” 2002 елның 27 декабрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2002, № 52 (1 өлеше), 5140 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

“Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2004, № 31, 3215 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

“Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2006, № 19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

“Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент” 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2008, № 30 (1 өлеше), 3579 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

“Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар

җыентыгы, 2008, № 52 (1 өл.), 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

“Энергияне саклау турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 261-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2009, № 48, 5711 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

“Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент” 2009 елның 30 декабрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 384-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2010, № 1, 5 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясендә дәүләт төзелеш күзәтчелеге турында” 2006 елның 1 февралендәге 54 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 54 номерлы карары) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2006, № 7, 774 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны һәм капиталь ремонтлауны гамәлгә ашырганда төзелеш контролен үткәрү тәртибе турында” 2010 елның 21 июнендәге 468 номерлы карары (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2010, № 26, 3365 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Аларны куллану нәтиҗәсендә “Биналарның һәм корылмаларның техник куркынычсызлыгы турында” Федераль закон таләпләренең үтәлеше зарури нигездә тәэмин ителә торган илкүләм стандартларны һәм кагыйдәләр җыелмасын (мондый стандартларның һәм кагыйдәләр җыелмасының өлешләре) исемлеген раслау турында” 2014 елның 26 декабрендәге 1521 номерлы карары (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2015, № 2, 465 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Бердәй тикшерүләр реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында” 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2015, № 19, 2825 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең “Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, капиталь ремонтлаганда башкарма документларның составына һәм аларны алып бару тәртибенә карата таләпләрне һәм эшләрне, конструкцияләрне, инженерия-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен таныклау актларына белдерелә торган таләпләрне раслау һәм гамәлгә кертү турында” 2006 елның 26 декабрендәге 1128 номерлы боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 2007 елның 06 мартында 9050 номеры белән теркәлгән) (алга таба – 26.12.2006 № 1128 Ростехнадзор боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнарының

норматив актлар бюллетене, 2007, № 13, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең “Дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең һәм төзелгән, үзгәртеп корылган, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объектларының техник регламентларның (нормаларның һәм кагыйдәләрнең), бүтән норматив-хокукый актларның, проект документациясенең таләпләренә җавап бирүе турында бәяләмәләр бирүнең тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында” 2006 елның 26 декабрендәге 1129 номерлы боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 2007 елның 06 мартында 9053 номеры белән теркәлгән) (алга таба – 26.12.2006 № 1129 Ростехнадзор боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене, 2007, № 15, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең “Дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда эшләрне формалаштыру һәм алып бару тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында” 2006 елның 26 декабрендәге 1130 номерлы боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 2007 елның 05 мартында 9009 номеры белән теркәлгән) (алга таба – 26.12.2006 № 1130 Ростехнадзор боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене, 2007, № 13, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең “Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, капиталь ремонтлаганда эшләр башкаруның гомуми һәм (яки) махсус журналын алып бару тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында” 2007 елның 12 гыйнварындагы 7 номерлы боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 2007 елның 06 мартында 9051 номеры белән теркәлгән) (алга таба – 12.01.2007 № 7 Ростехнадзор боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене, 2007, № 14);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында” Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру турында” 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 2009 елның 13 маенда 13 915 номеры белән теркәлгән) (алга таба – РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 30.04.2009 № 141 боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының “Төзелешкә рөхсәт рәвешен һәм объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт рәвешен раслау турында” 2015 елның 19 февралендәге 117/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгының 19.02.2015 № 117/пр боерыгы) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2013, № 47, 6117 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның “Стандартлаштыру өлкәсендә аларны ирекле нигездә куллану нәтиҗәсендә

“Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент” 2009 елның 30 декабрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренең үтәлеше тәэмин итеlә торган документлар исемлеген раслау турында” 2015 елның 30 мартындагы 365 номерлы боерыгы (Норматив, методик һәм типик проект документлары турында мәгълүмати бюллетень, 2015, № 5, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе мәсьәләләре” 2007 елның 12 ноябрендәге 622 номерлы карары (алга таба –622 номерлы ТР МК карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2007, № 43, 1707 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт вазыйфаларын үтәүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында” 2012 елның 31 декабрендәге 1192 номерлы карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2013, № 7, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Төзелеше өчен төзелешкә рөхсәтләр бирү таләп ителми торган объектлар исемлеген раслау турында” 2011 елның 24 июнендәге 1038-р номерлы боерыгы (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2011, № 33, 1617 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).”;

4. 1.6 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) таләпләр үтәлешен, алар нигезендә:

а) төзүче, техник заказчы белән төзелгән капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору турында шартнамәләр (алга таба шулай ук – төзелеш подряды шартнамәсе) буенча эшләр, әгәр дә РФ ШрК 52 статьясында башкача билгеләнмәсә, капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору өлкәсендә үзеннән-үзе җайга салынулы оешмаларның әгъзалары булган шәхси эшкуарлар яисә юридик затлар тарафыннан гына башкарылырга тиеш. Мондый шартнамәләр буенча капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору буенча эшләр башкару төзелешне оештыру буенча белгечләр (проектларның баш инженерлары) тарафыннан тәэмин ителә. Бүтән затлар белән төзелгән капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору турындагы шартнамәләр буенча эшләр мондый үзеннән-үзе җайга салынулы оешмаларның әгъзалары булмаган шәхси эшкуарлар яисә юридик затлар тарафыннан башкарыла ала;

б) капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашыручы зат (алга таба – төзүне гамәлгә ашыручы зат) булып төзелеш подряды шартнамәсен төзегән төзүче яисә шәхси эшкуар яки юридик зат

тора ала. Төзүне гамәлгә ашыручы зат проект документларының, техник регламентларның таләпләренең, күрсәтелгән эшләр барышында куркынычсызлык техникасының үтәлешен тәэмин итә һәм башкарылган эшләрнең сыйфаты һәм аларның проект документлары таләпләренә туры килүе өчен җаваплы була;

в) төзүче капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны, әгәр дә РФ ШрК 52 статьясында башкача каралмаса, ул капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору өлкәсендә үзеннән-үзе җайга салынулы оешма әгъзасы булу шарты белән, мөстәкыйль рәвештә яисә төзелеш подряды шартнамәсе буенча бүтән затларны җәлеп итеп гамәлгә ашырырга хокуклы.

Техник регламентлар булмаган очракта башкарыла торган эшләрнең, кулланыла торган төзелеш материалларының һәм мондый эшләрнең нәтиҗәләренең төзелеш нормаларына һәм кагыйдәләренә, атом энергиясеннән файдалану өлкәсендәге федераль нормаларга һәм кагыйдәләргә, санитария-эпидемиология кагыйдәләренә һәм нормативларына, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләргә, энергетика нәтиҗәлелегенә карата таләпләргә капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителешенә карата таләпләргә, мәдәни мирас объектларын дәүләти саклау таләпләренә һәм мәдәни мирас объектларын саклауга карата таләпләргә, гражданлык оборонасының инженерия-техник тәэминат чаралары нормаларына һәм кагыйдәләренә, сәнәгать куркынычсызлыгы таләпләренә, электр энергетикасында ышанычлылык һәм куркынычсызлык таләпләренә, гидротехника корылмаларының куркынычсызлык нормаларына һәм кагыйдәләренә, бүтән төрле куркынычсызлык кагыйдәләренә һәм дәүләт стандартларына, шулай ук капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда зарури үтәлергә тиешле Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актларының һәм федераль башкарма хакимият органнарының норматив-хокукый актларының таләпләренә (алга таба – нормалар һәм кагыйдәләр) җавап бирүен тикшерү дәүләт төзелеш күзәтчелегенең предметы булып тора.

Бу Регламентта кулланыла торган “төзүче”, “техник заказчы”, “төзүне гамәлгә ашыручы зат” төшенчәләре һәм “юридик зат”, “шәхси эшкуар” төшенчәләре тигез мәгънәле.”.

5. 1.9 пунктында:

а) 2 пунктта “һәм Россия Федерациясе законнарына туры килми торган” сүзләрен “, шулай ук зарури кулланылышы Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документларның таләпләре үтәлешен” сүзләренә алмаштырырга;

б) 11 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“юридик заттан, шәхси эшкуардан тикшерүне үткәрә башлау датасына кадәр документлар, мәгълүматлар бирүне таләп итәргә. Тикшерү үткәрү турында боерык кабул ителгәннән соң вазыйфаи затлар ведомствоара

мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматларны соратырга хокуклы;”;

в) түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:

“12) урынга чыгып тикшерү үткәргәндә юридик заттан, шәхси эшкуардан документар тикшерүне үткәргәндә алар тарафыннан тапшырылган документларның һәм (яки) мәгълүматларның тапшырылуын таләп итү тыела.”.

6. 2 бүлектәге 1 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1 таблица – Территориаль органнар турында белешмәләр

| Территориаль орган | Адресы | Телефоны |
|---|---|---|
| Автоюлларны һәм юл буе төзелешен күзәтү буенча территориаль орган | Казан ш.,<br>Декабристлар ур., 81 | (843) 518-81-60 |
| Капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны күзәтү буенча төбәк органы | Казан ш.,<br>Декабристлар ур., 81 | (843) 518-83-44 |
| Капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны күзәтү буенча төньяк-көнбатыш территориаль орган | Лаеш ш.,<br>М. Ульянова ур., 54 | (84378) 2-55-03 |
| Капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны күзәтү буенча төньяк-көнчыгыш территориаль орган | Чаллы ш.,<br>Шамил Усманов ур., 57а | (8552) 52-74-52 |
| Капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны күзәтү буенча көнчыгыш территориаль орган | Түбән Кама ш.,<br>Җиңүгә 30 ел ур., 7 й. | (8555) 30-15-31 |
| Капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны күзәтү буенча Кама арты территориаль органы | Чистай ш.,<br>Толстой ур., 157 | (84342) 5-45-69 |
| Капиталь төзелеш объектларын төзүне, | Әлмәт ш.,<br>Шевченко ур., 88 й. | (8553) 33-80-82 |

| | | |
|---|---|---|
| үзгәртеп коруны күзәтү буенча көньяк-көнчыгыш территориаль орган | | |
| Капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны күзәтү буенча көнбатыш территориаль орган | Яшел Үзән ш., Норкин ур., 6 | 8 (84371)47095 |
| Экспертизаларны, тикшерүләрне һәм сынауларны үткәрүне күзәтү буенча территориаль орган | Казан ш., Декабристлар ур., 81 | (843) 518-81-60 |

”.

7. 2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2.9. Зарури таләпләрне бозуларны профилактикалау максатларында Инспекциянең рәсми интернет-сайтында түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:

а) ел саен раслана торган бозуларны профилактикалау программасы;

б) контрольлекнең предметы булып аларның үтәлешен бәяләү булган, зарури таләпләрне үз эченә ала торган норматив-хокукый актларның яисә аларның аерым өлешләренең исемлеге, шулай ук тиешле норматив-хокукый актларның текстлары;

в) зарури таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шул исәптән зарури таләпләрне үтәү буенча бастырып чыгарылган кулланмалар турында мәгълүмат, семинарлар һәм конференцияләр үткәрү, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшен алып бару турында белешмәләр, бүтән ысуллар белән урнаштырыла торган башка төрле мәглүматлар турында белешмәләр. Зарури таләпләр үзгәртелгән очракта зарури таләпләрне билгели торган яңа норматив-хокукый актларның эчтәлеге, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләр, аларның гамәлгә керү вакытлары һәм тәртибе турында аңлатмалар, шулай ук зарури таләпләрне кертүгә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән кирәкле оештыру, техник чараларны үткәрү турында киңәшләр урнаштырыла;

г) даими рәвештә, елына бер мәртәбәдән ешрак булмаган дәрәҗәдә башкарыла торган, контрольлекне гамәлгә ашыру тәҗрибәсен гомумиләштерү буенча белешмәләр, шул исәптән мондый бозуларга юл куймау максатларында юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан күрелергә тиешле чараларга карата киңәшләр белән иң еш очрый торган зарури таләпләрне бозу очракларын күрсәтеп.”.

8. 2.14 пунктның 2 пунктчасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Инспекциягә мөрәҗәгать итүче затны билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук 2.14 пунктында күрсәтелгән фактлар турында белешмәләрне үз эченә алмый торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә алмый. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар бары тик алар мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең бердәй интентификацияләү һәм аутентификацияләү системасында зарури авторлаштырылуын күздә тотучы мәгълүмати-коммуникация технология чараларыннан файдаланылып җибәрелгән булу шарты белән генә планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә алалар”.

9. 3 бүлектәге 2 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2 таблица – Юридик затларга, шәхси эшкуарларга белдерелә торган зарури таләпләр исемлеге

| Контрольлек субъектлары | Зарури таләпнең тәгъбире | Зарури таләпне билгели торган норматив-хокукый акт |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Төзүче, техник заказчы, төзүне гамәлгә ашыручы зат | 1. Төзелешкә рөхсәт булу | РФ ШрК 51 ст. 2 өл., Россия Төзелеш министрлыгының 19.02.2015 № 117/пр боерыгы |
| | 2. Инспекциягә проект документларын тулы күләмдә, ә төзелешнең, үзгәртеп коруның аерым этабына рөхсәт бирелү очрагында, тиешле төзелеш этабын гамәлгә ашыру өчен кирәкле күләмдә тапшыру. | РФ ШрК 52 ст. 5 өл. |
| | 3. Проект документларына уңай экспертиза бәяләмәсе булу | РФ ШрК 52 ст. 5 өл. |
| | 4. Инспекциягә кызыл линияләрдән җирлеккә аерып чыгару линиясен кертү турында документ тапшыру | РФ ШрК 52 ст. 5 өл. |
| | 5. Башкарылган эшләрнең исәбе алып барыла торган гомуми һәм махсус журналларны алып бару, саклау, Инспекциягә тапшыру | РФ ШрК 52 ст. 5 өл.; РФ Хөкүмәтенең № 54 карарының 24 п.; 12.01.2007 № 7 Ростехнадзор боерыгының 8 п., 10 п. |
| | 6. Инспекциягә үзеннән-үзе җайга салынулы оешмада әгъза булып торуны яисә үзеннән-үзе җайга салынулы оешмада әгъзалык булуын кирәклеге юклыгын раслый торган документларны | РФ ШрК 52 ст. 2, 2.1, 2.2, 3.1 өл.; ТР МК № 622 карарының 4.1.3. |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшыру | п. |
| | 7. Инспекциягә төзелешне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру өчен җәлеп ителгән затлар белән шартнамәләр тапшыру | РФ ШрК 52 ст. 5 өл.; ТР МК № 622 карарының 4.1.3 п. |
| | 8. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшчәнлек башкаруга, шул исәптән, мәдәни мирас объектын саклау буенча мондый объектның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык сыйфатламаларына кагыла торган реставрацияләү эшләрен башкаруга лицензия булу | № 73-ФЗ Федераль законның 45 ст. 6 өл. |
| | 9. Инспекциягә башкарылган эшләрнең нәтиҗәләрен, эшләрне, конструкцияләрне, инженерия-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен, кулланыла торган төзелеш материалларының үрнәкләрен (пробаларын) таныклау актларын тапшыру | № 54 РФ Хөкүмәте карарының 24 п. |
| | 10. Башкарма документларны алып бару, саклау, Инспекциягә тапшыру | РФ ШрК 52 ст. 6 өлеше; № 54 РФ Хөкүмәте карарының 24 п.; 26.12.2006 № 1128 Ростехнадзор боерыгының 4 п., 5 п. |
| | 11. Капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда тикшерелергә тиешле эшләрнең төгәлләнү вакытлары турында Инспекциягә хәбәрләмә җибәрү | РФ ШрК 52 ст. 6 өл. |
| | 12. Капиталь төзелеш объектында барлыкка килгән һәр аварияле вакыйга очрагы турында хәбәрләмә җибәрү | РФ ШрК 53 ст. 3 өл.; 26.12.2006 № 1129 Ростехнадзор боерыгының 8 п. |
| | 13. Тикшерелергә тиешле эшләрнең тәмамлану вакытлары үзгәрүе хакында Инспекциягә хәбәрләмә җибәрү, әгәр дә мондый эшләрне төгәлләү вакыты тикшерүләрне үткәрү программасында күрсәтелгән вакытларга туры килмәсә | 26.12.2006 № 1129 Ростехнадзор боерыгының 3 п., 8 п. |
| | 14. Капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда җитешсезлекләрне юкка чыгару турында Инспекциягә хәбәрләмә җибәрү | 26.12.2006 № 1129 Ростехнадзор боерыгының 16 п. |
| | 15. Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору процессында проект документларының, техник регламентларның таләпләре, куркынычсызлык техникасы үтәлешен тәэмин итү, башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен җаваплы булу һәм аларның проект документлары таләпләренә җавап бирүе | РФ ШрК 52 ст. 3 өл. |

| | | |
|---|---|---|
| | 16. Капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны төзүченең яисә техник заказчының (төзүне, үзгәртеп коруны төзелеш подряды шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашырганда) биреме, проект документлары, капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата төзелешкә рөхсәт алу өчен җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын тапшыру датасына билгеләнгән таләпләр, җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану, Россия Федерациясенең җир турында һәм башка төрле законнары нигезендә билгеләнгән чикләмәләр, техник регламентларның таләпләре нигезендә гамәлгә ашыру һәм шул ук вакытта өченче затлар һәм әйләнә-тирә мохит өчен эшләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү, хезмәт куркынычсызлыгы, мәдәни мирас объектлары саклану таләпләрен үтәү. | РФ ШрК 52 ст. 6 өл. |
| | 17. Төзелеш контрольлеген үткәрү | РФ ШрК 52 ст. 6 өл.; РФ ШрК 53 ст. 2 өл. |
| | 18. Капиталь төзелеш объектының куркынычсызылыгына йогынты ясый торган һәм төзү, үзгәртеп кору технологиясе нигезендә аларның башкарылышын контрольдә тоту башка эшләрне башкарганнан соң үткәрелә алмый торган эшләрнең башкарылуына, шулай ук, әгәр дә төзелеш контрольлеген үткәрү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне башка төзелеш конструкцияләрен һәм инженерия-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен сүтмичә яисә аларга зыян салмыйча мөмкин булмаса, төзелеш конструкцияләренең һәм инженерия-техник тәэминат челтәрләре өлешләренең куркынычсызлыгына карата, күрсәтелгән эшләрнең, конструкцияләрнең һәм челтәрләрнең өлешләренең техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә җавап бирүенә карата контрольлек үткәрү. Күрсәтелгән эшләрне, конструкцияләрне, инженеия-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен таныклау актларын төзү | РФ ШрК 53 ст. 4 өл. |
| | 19. Капиталь төзелеш объектының куркынычсызылыгына йогынты ясый торган һәм төзү, үзгәртеп кору технологиясе нигезендә аларның башкарылышын контрольдә тоту башка эшләрне башкарганнан соң үткәрелә алмый торган барлык эшләрнең башкарылуына карата контрольлек үткәрү, шулай ук проект документларында, техник регламентларның таләпләре нигезендә каралган очракларда мондый конструкцияләргә карата сынаулар үткәрелергә тиеш. Күрсәтелгән эшләрне, конструкцияләрне, инженерия-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен | РФ ШрК 53 ст. 4 өл. |

| | | |
|---|---|---|
| | таныклау актларын төзү | |
| | 20. Башкарылган эшләргә һәм кулланыла торган төзелеш материалларына тикшерүләр, сынаулар, экспертизалар үткәрү, әгәр дә бу эш төзелеш контрольлеген үткәргәндә таләп ителсә, ләкин гамәлгә ашырылмаган булса | РФ Хөкүмәтенең № 54 карарының 24 п. |
| Төзүне гамәлгә ашыручы зат | 21. Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору гамәлгә ашырыла торган территориягә төзүченең яисә техник заказчының, Инспекция вәкилләренең керә алу мөмкинлеген тәэмин итү, аларга кирәкле документларны тапшыру, башкарма документларны алып баруны тәэмин итү, төзүчегә яисә техник заказчыга, Инспекциягә тикшерүгә тиешле эшләрне тәгәлләү вакытлары турында хәбәр итү, ачыкланган җитешсезлекләрнең юкка чыгарылуын тәэмин итү, ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару турында актлар төзелгәнчегә кадәр эшләр башкаруга керешүгә тыюны үтәү, кулланыла торган төзелеш материалларының сыйфаты өчен контрольлек тәэмин итү | РФ ШрК 52 ст. 6 өл. |
| | 22. Төзелешнең барлык процессы дәвамында кулланыла торган төзелеш материалларының һәм эшләнмәләрнең, шул исәптән төзелеш гамәлгә ашырыла торган территориядә җитештерелә торган төзелеш материалларының № 384-ФЗ Федераль законның, проект документларының таләпләренә җавап бирүен контрольдә тоту. | № 384-ФЗ Федераль законның 34 ст. 1 өл., 3 өл. |
| Төзүче | 23. Бинаның, төзелмәнең, корылманың энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм аларның кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеше таләпләренә җавап бирүен оптималь архитектура, вазыйфаи-технологик, конструктив һәм инженерия-техник тәэминат чишелешләрен табу һәм төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда аларның тиешенчә тормышка ашырылу юлы белән тәэмин итү | № 261-ФЗ Федераль законның 11 ст. 7 өл. |
| Төзүче, техник заказчы | 24. Проект документларын раслау | РФ ШрК 48 ст. 15 өл. |
| | 25. Проект документларын һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләрен дәүләт экспертизасына яисә дәүләти булмаган экспертизага җибәрү | РФ ШрК 48 ст. 15 өл.; РФ ШрК 49 ст. 1 өл. |
| | 26. Җир кишәрлеген төзү өчен һәм капиталь төзелеш объектын үзгәртеп кору өчен әзерләү, төзүне гамәлгә ашыручы затка инженерлык эзләнүләре материалларын, проект документларын, төзелешкә рөхсәтне тапшыру | РФ ШрК 52 ст. 4 өл. |
| | 27. Эшләрне туктату яисә аларны алты айдан артык вакытка туктату зарурлыгы булганда капиталь төзелеш объектын консервацияләүне тәэмин итү | РФ ШрК 52 ст. 4 өл. |
| | 28. Капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы башланганчыга кадәр җиде эш | РФ ШрК 52 ст. 5 өл.; 26.12.2006 |

| | | |
|---|---|---|
| | көненнән дә соңга калмыйча Инспекциягә, мондый эшләрне башлануы турында кирәкле документларны теркәп, хәбәрләмә җибәрү | № 1129 Ростехнадзор боерыгының 5 п. |
| | 29. Капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы фактик рәвештә тәмамлангач, капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда җибәрелгән барлык бозуларны бетергәч, капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча барлык эшләрне башкаруга, шулай ук төзелеш материалларының (эшләнмәләрнең) кулланылышына бәйле булган башкарма документларны рәсмиләштергәч, Инспекциягә төзелеш тәмамлану турында хәбәрләмә җибәрү | РФ ШрК 54 ст. 5 өл.; 26.12.2006 № 1129 Ростехнадзор боерыгының 25 п. |
| | 30. Төзүне гамәлгә ашыручы затларга тикшерүләрне үткәрү программасында каралган тикшерүләр турында белешмәләр җиткерү | 26.12.2006 № 1129 Ростехнадзор боерыгының 7 п. |
| | 31. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы вазыйфаи заты РФ ШрК 54 статьясында, РФ Хөкүмәтенең № 54 карарының 24 пунктында каралган үз вәкаләтләрен үтәсен өчен, шул исәптән төзүче яисә техник заказчы белән шартнамә нигезендә төзүне гамәлгә ашыручы затлар аша, шартлар тәэмин итү | 26.12.2006 № 1129 Ростехнадзор боерыгының 10 п. |
| | 32. Тиешле экспертизаларны, тикшерүләрне, лаборатор һәм башка сынауларны үткәрү өчен, шул исәптән төзүне гамәлгә ашыручы затлар аша, шартлар тәэмин итү | 26.12.2006 № 1129 Ростехнадзор боерыгының 23 п. |

”.

10. 4 бүлектә 3 таблицаның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“үзеннән-үзе җайга салынулы оешмада әгъза булып торуны яисә үзеннән-үзе җайга салынулы оешмада әгъза булып торуның кирәк булмавын раслый торган документлар”.

11. 5.1 пунктында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда дәүләт вазыйфасын үтәүне туктату рөхсәт ителә.”

12. 5.5 пунктының унберенче абзацында “бер эш көне” сүзләрен “өч эш көне” сүзләренә алмаштырырга.

13. 5.11 пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыруны оештыру һәм аңа әзерлек” административ процедурасын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча мәгълүмат Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан гамәлгә ашырыла торган контрольлек һәм күзәтчелек процессын автоматлаштыру буенча “ТР Төзелеш күзәтчелеге АМС” мәгълүмат системасында (алга таба – “ТР Төзелеш күзәтчелеге АМС”) процедура тәмамланганнан соң 10 эш көне дәвамында урнаштырылырга

тиеш. “ТР Төзелеш күзәтчелеге АМС” сайтына сылтама Инспекциянең рәсми сайтында бар.”.

14. 5.15 пунктның беренче абзацында “яисә башка төрле үтемле ысул белән” сүзләрен “һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресы буенча җибәрелгән электрон документ ярдәмендә, әгәр дә мондый адрес юридик затларның бердәй дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәй дәүләт реестрында тиешенчә урнаштырылган булса яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Инспекциягә элегрәк тапшырылган булса, яисә башка төрле үтемле ысул белән”.

15. 5.19 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Документар тикшерү барышында вазыйфаи затлар иң беренче чиратта төзүче, техник заказчы, төзүне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан тапшырылган документларны, күзәтчелек эше материалларын, шул исәптән капиталь төзелеш объектының проект документларын, алдагы тикшерүләрнең актларын, административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау материалларын һәм төзүчегә, техник заказчыга яисә төзүне гамәлгә ашыручы затка карата Инспекция карамагында булган, гамәлгә ашырылган дәүләт төзелеш күзәтчелеге нәтиҗәләре турындагы башка документларны карыйлар.

Әгәр дә, документар тикшерү барышында тапшырылган документларда хаталар һәм (яисә) каршылыклар ачыкланса яисә бу документларда булган белешмәләрнең Инспекциядә булган документлардагы белешмәләргә туры килмәве билгеле булса, вазыйфаи зат 10 эш көне эчендә язмача рәвештә кирәкле аңлатмаларны тапшыру таләбе белән нигезле гарызнамә әзерли һәм билгеләнгән тәртиптә аны төзүчегә, техник заказчыга яисә төзүне гамәлгә ашыручы затка җибәрә. Гарызнамәгә Инспекция башлыгының, башлыгы урынбасарының тикшерү үткәрү турында боерыгының мөһер белән таныкланган күчермәсе теркәлә.

Нигезле гарызнамәне алганнан соң ун эш көне эчендә төзүче, техник заказчы яисә төзүне гамәлгә ашыручы зат гарызнамәдә күрсәтелгән документларны Инспекциягә җибәрергә бурычлы.

Гарызнамәдә күрсәтелгән документлар мөһер (ул булган очракта) һәм төзүченең, техник заказчының яисә төзүне гамәлгә ашыручының, аларның вәкаләтле затларының тиешенчә имзасы белән таныкланган күчермәләр рәвешендә тапшырыла. Төзүче, техник заказчы яисә төзүне гамәлгә ашыручы зат гарызнамәдә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә җибәрергә хокуклы.

Әгәр дә тапшырылган аңлатмаларны һәм документларны караганнан соң яисә аңлатмалар булмаган очракта, зарури таләпләрне бозу билгеләре билгеләнсә, вазыйфаи зат (төркем җитәкчесе) урынга чыгып тикшерү үткәрү турында боерык проектын әзерләү юлы белән урынга чыгып тикшерү үткәрү инициативасы белән чыгарга хокуклы. Урынга чыгып тикшерү үткәрү турында карарны Инспекция башлыгы, башлык урынбасары кабул итә.

Урынга чыгып тикшерү үткәргәндә юридик заттан, шәхси эшкуардан документар тикшерүне үткәрү барышында алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматларны таләп итү рөхсәт ителми.

Тикшерүне үткәргәндә Инспекция төзүчедән, техник заказчыдан яисә төзүне гамәлгә ашыручы заттан тикшерү предметына карамый торган белешмәләрне һәм документларны, шулай ук Инспекция тарафыннан башка органнардан һәм (яки) оешмалардан алынырга мөмкин булган белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуклы түгел. Зарурлык килеп туганда, вазыйфаи затлар документларны һәм (яки) мәгълүматларны, шул исәптән электрон рәвештә, шушы Регламентның 1.7 пунктының 9 һәм 10 пунктчаларындагы таләпләргә туры китереп, билгеләнгән тәртиптә сораталар һәм алалар.

“Документар тикшерү” гамәленең нәтиҗәсе: контрольлек чараларын үткәрү.

Үтәү вакыты: 20 эш көненнән артык түгел.”.

16. Түбәндәге эчтәлекле 5.20 пунктын өстәргә:

“5.20. Төзүче, техник заказчы яисә төзүне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыручы законда каралганча тапшырылырга тиешле һәм зарури булган белешмәләр (мәгълүматлар) тапшырылмаганда яисә үз вакытында тапшырылмаганда, яисә Инспекциягә мондый белешмәләр (мәгълүматлар) тулы булмаган күләмдә яисә ялган рәвештә тапшырылганда, РФ КоАП каралган тәртиптә, РФ КоАП 19.7 статьясы буенча административ хокук бозу турында эш кузгатыла.”.

17. 5.22 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Объектка чыгуны гамәлгә ашырыр алдыннан вазыйфаи зат, төркем җитәкчесе күзәтчелек эше материаллары, шулай ук объектның проект документлары белән танышырга бурычлы.

Зарурлык булганда, вазыйфаи зат документларны һәм (яки) мәгълүматларны, шул исәптән электрон рәвештә, шушы Регламентның 1.7 пунктының 9 һәм 10 пунктчаларындагы таләпләргә туры китереп, билгеләнгән тәртиптә сората һәм ала.

Әгәр дә урынга чыгып тикшерүне үткәрү шәхси эшкуарның, ваның вәкаләтле затының, юридик зат җитәкчесенең яисә башка вазыйфаи затының булмавына бәйле рәвештә яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан фактта эшчәнлекнең гамәлгә ашырылмавына бәйле рәвештә, яисә шәхси эшкуарның, аның вазыйфаи затының, юридик зат җитәкчесенең яисә бүтән вазыйфаи затының тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавына китерүче башка гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында мөмкин булмаслык итеп килеп чыкса, Инспекциянең тикшерүне үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи заты тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында, аны үткәрүнең мөмкин булуына китерүче сәбәпләрне күрсәтеп, акт төзи. Бу очракта Инспекция, тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында акт төзелгән көннән башлап өч ай эчендә шушы юридик затка, шәхси эшкуарга

карата, юридик затка, шәхси эшкуарга алдан хәбәр итмичә, урынга чыгып тикшерү үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.”.

18. 5.27 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“үзеннән-үзе җайга салынулы оешмада әгъза булып торуны яисә үзеннән-үзе җайга салынулы оешмада әгъза булып торуның кирәк булмавын раслый торган документлар.”.

19. 5.32 пунктының өченче абзацында:

а) “08.07.2013 ел, № 67” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) “контроль тикшерүләрне” сүзләрен “контрольлек чаралары” сүзләренә алмаштырырга.

20. 5.33 пунктының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Капиталь төзелеш объектына тикшерү әзерләү һәм үткәрү” административ процедурасын үткәрү нәтиҗәләре турындагы тиешле мәгълүматлар җаваплы башкаручы тарафыннан “ТР Төзелеш күзәтчелеге АМС” системасында формалаштырыла, белешмәләр БТРына Инспекциянең вәкаләтле затлары тарафыннан № 294-ФЗ Федераль законның 13.3 статьясында һәм РФ Хөкүмәтенең № 415 карарында билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда кертелә. БТР сайтына сылтама Инспекциянең рәсми сайтында “Дәүләт күзәтчелеге (контрольлеге)” бүлегендә бар.”.

21. 5.39 пунктының бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү” административ процедурасы нәтиҗәләре турындагы тиешле мәгълүматлар җаваплы башкаручы тарафыннан “ТР Төзелеш күзәтчелеге АМС” системасында формалаштырыла, белешмәләр БТРына Инспекциянең вәкаләтле затлары тарафыннан № 294-ФЗ Федераль законның 13.3 статьясында һәм РФ Хөкүмәтенең № 415 карарында билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда кертелә. БТР сайтына сылтама Инспекциянең рәсми сайтында “Дәүләт күзәтчелеге (контрольлеге)” бүлегендә бар.”.

22. 5.50 пунктының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Ачыкланган бозуларны юкка чыгару буенча чаралар күрү” административ процедурасы нәтиҗәләре турындагы тиешле мәгълүматлар җаваплы башкаручы тарафыннан “ТР Төзелеш күзәтчелеге АМС” системасында формалаштырыла, белешмәләр БТРына Инспекциянең вәкаләтле затлары тарафыннан № 294-ФЗ Федераль законның 13.3 статьясында һәм РФ Хөкүмәтенең № 415 карарында билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда кертелә. БТР сайтына сылтама Инспекциянең рәсми сайтында “Дәүләт күзәтчелеге (контрольлеге)” бүлегендә бар.”.

23. 5.57 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Төзелеше тәмамланган капиталь төзелеш объектын тикшерү” административ процедурасы нәтиҗәләре турындагы тиешле мәгълүматлар җаваплы башкаручы тарафыннан “ТР Төзелеш күзәтчелеге АМС” системасында формалаштырыла, белешмәләр БТРына Инспекциянең вәкаләтле затлары тарафыннан № 294-ФЗ Федераль законның 13.3

статьясында һәм РФ Хөкүмәтенең № 415 карарында билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда кертелә. БТР сайтына сылтама Инспекциянең рәсми сайтында “Дәүләт күзәтчелеге (контрольлеге)” бүлегендә бар.”.

24. 8 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасында
Татарстан Республикасы Дәүләт
төзелешен күзәтү инспекциясе
тарафыннан төбәк дәүләт төзелеш
күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча
дәүләт вазыйфасын үтәүнең
административ регламентына
8 нче кушымта
(рәвеше)

___________________________________________________________________________
(дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге) органының яисә муниципаль контрольлек органының аталышы)

**БОЕРЫК**
**_____________________ тикшерү үткәрү турында**
(документар/урынга чыгып)

20____ елның “__”_________ №_____________

1. ___________________________________________________________________
(объектның аталышы)

___________________________________________________капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча, мәдәни мирас объектын саклау буенча, мондый объектның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык сыйфатламаларына тия торган эшләрне башкару буенча (кирәклесен күрсәтергә) эшчәнлекне гамәлгә ашыручы__________________

___________________________________________________________________________
(юридик затның (филиалының, вәкиллегенең) аталышы),

___________________________________________________________________________
(шәхси эшкуарның, физик затның фамилиясе, исеме һәм (булган очракта) атасының исеме һәм юридик адресы (теркәлү адресы), реквизитлары)

_____________________________________________ карата тикшерү үткәрергә.

2. Урнашкан урыны: __________________________________________________
(капиталь төзелеш объектының почта яки төзелеш адресы)

3. Түбәндәге затларны тикшерү үткәрү өчен вәкаләтле итеп билгеләргә:___

___________________________________________________________________________
(тикшерү үткәрү вәкаләте бирелгән вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы)

4. Түбәндәге затларны экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре сыйфатында тикшерү үткәрүгә җәлеп итәргә:______________________________
_____________________________________________________________________________
(тикшерүне үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфалары, аккредитация турындагы таныклык реквизитларын һәм аккредитация турында таныклык биргән аккредитацияләүче органның аталышын күрсәтеп)

5. Бу тикшерү_____________________________________________________________
(дәүләт контрольлегенең (күзәтчелегенең) төренең (төрләренең) аталышы, вазыйфа(лар)ның “Федераль дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (вазыйфалар) реестры” федераль дәүләт мәгълүмат системасындагы реестры номер(лар)ы)
_______________________________________________кысаларында үткәрелә.

6. Билгеләргә:
бу тикшерү_______________________________________________________
___________________________________________максаты белән үткәрелә.

Үткәрелә торган тикшерүнең максатлары билгеләнгән очракта түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:
а) Тикшерүләр программасы буенча тикшерү үткәргәндә:
– Программага сылтама;
б) Россия Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясының 5 һәм 6 өлеше нигезендә төзүче (заказчы) тарафыннан Инспекциягә җибәрелгән хәбәрләмәләр, шулай ук бозуларны юкка чыгару турында, төзелешне тәмамлау турында хәбәрләмәләр килүгә бәйле рәвештә тикшерү үткәрелгән очракта:
– хәбәрләмә реквизитлары;
в) бирелгән күрсәтмәне үтәү вакыты узгач урынга чыгып үткәрелә торган тикшерү очрагында:
– тикшерелә торган затка элегрәк бирелгән, үтәү вакыты узган ачыкланган бозуны юкка чыгару турында күрсәтмә реквизитлары;
г) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 53 статьясының 3 өлеше нигезендә гражданнардан, юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан, шулай ук төзүне гамәлгә ашыручы затлардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан барлыкка килгән авария очраклары, техник регламентларны һәм проект документлары таләпләрен бозулар турында мәгълүмат килеп ирешкән очракта, әгәр дә мондый бозулар кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, мөлкәтенә зыян салу куркынычын тудырса, яисә мондый зыян салынуга китереп чыгарса:
– гражданнардан, юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан килгән мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларның реквизитлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан килгән мәгълүматлар турында белешмәләр;
д) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре нигезендә яисә прокурорның прокуратура органнарына килгән

материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешен күзәтү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы таләпләренә нигезләнеп, Инспекция башлыгының (башлыгы урынбасарының) боерыгы очрагында:
– Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре нигезендә тикшерү үткәрү турында боерык чыгарган җитәкченең, җитәкче урынбасарының боерыгы (әмере) реквизитлары;
– прокурорның прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешен күзәтү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы таләбе реквизитлары;
е) прокуратура органнары белән килештерелергә тиешле, ләкин кичектергесез чаралар күрелү максатларында, зыян китерелүгә яисә тикшерелә торган таләпләрнең бозылуына бәйле рәвештә кичекмәстән үткәрелергә тиешле планнан тыш урынга чыгып тикшерү очрагында, әгәр дә мондый зыян китерелү яисә таләпләрнең бозылуы турыдан-туры аны кылу мизгелендә ачыкланса:
– тикшерү үткәрү турында әмергә (боерыкка) текәлә торган, бозу очрагын ачыклаган вазыйфаи зат тарафыннан тапшырылган документ (рапорт, доклад язуы һәм башкалар) күчермәсенең реквизитлары;

Бу тикшерүнең бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:___________________
__________________________________________________________________

7. Бу тикшерүнең предметы булып тора (кирәклесен сайларга):
□зарури таләпләрнең үтәлеше;
□ Инспекция күрсәтмәләренең үтәлеше;
□ түбәндәге чараларны үткәрү:
□ гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясенең Архив фондындагы аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган, илкүләм китапханә фонды составына керә торган документларга, дәүләт иминлегенә зыян салынуны, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы белән яный торган очракларны булдырмау, шулай ук гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре нигезсез чикләнүгә юл куймау буенча;
□ табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтү буенча;
□ дәүләт иминлеген тәэмин итү буенча;
□ мондый зыян салыну нәтиҗәләрен юкка чыгару буенча.

8. Тикшерүне үткәрү вакыты:_______________________________________

Тикшерүне үткәрә башлауга
20___ елның “___”________________ керешергә.
Тикшерүне
20___ елның “___”_______________ соңга калмыйча тәмамларга.

9. Тикшерүне үткәрүнең хокукый нигезләре:____________________________
_____________________________________________________________________
(тикшерү шуңа нигезләнеп үткәрелә торган норматив-хокукый акт нигезләмәсенә сылтама)

10. Тикшерелергә тиешле зарури таләпләр:______________________________
_____________________________________________________________________

11. Тикшерүне үткәрү барышында контрольлек буенча, тикшерүне үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле булган түбәндәге чараларны үткәрергә (контрольлек чарасының аталышын һәм аны үткәрү вакытларын күрсәтеп):_____________________________________________
_____________________________________________________________________

12. Дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турында нигезләмәләрнең, контрольлек чараларын үткәрүнең тикшерүне үткәрү өчен кирәкле булган административ регламентларының (булган очракта), хезмәттәшлек итүнең административ регламентларының (булган очракта) исемлеге:_______________________________________________________
_____________________________________________________________________
(аталышларын, номерларын һәм аларны кабул итү даталарын күрсәтеп)

13. Тикшерүне үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен зат, шәхси эшкуар, физик зат тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның исемлеге:_________________________________________
_____________________________________________________________________

_____________________________
_____________________________
(тикшерүне үткәрү турында әмер
биргән җитәкченең (җитәкче урынбасарының)
вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары)
(мөһер белән таныкланган имзасы)

_____________________________
_____________________________
(әмер проектын турыдан-туры әзерләгән
вазыйфаи затның фамилиясе, исеме,
атасының исеме (булган очракта),
элемтә телефоны, электрон адресы (булган очракта)

**Искәрмә**: Әгәр дә тикшерү төзелешне, үзгәртеп коруны, мәдәни мирас объектын саклау буенча мондый объектның конструктив һәм башка

ышанычлылык сыйфатламаларына тия торган эшләрне тәмамлау турында килгән хәбәрләмә нигезендә үткәрелгән очракта, документ аталышында “тикшерү” сүзе алдыннан “төзелеше тәмамланган капиталь төзелеш объектын” сүзләре өстәлә.

Тикшерү Регламентның 2.14 п. 2, 4.5 п.п. күрсәтелгән нигезләрдә үткәрелгән очракта, баш исемдә документар/урынга чыгып сүзләре алдыннан “планнан тыш” сүзләре күрсәтелә.